Татарстан Республикасы Хисап палатасы

2016 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге турында Хисап

Казан – 2017 ел

Эчтәлек

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге.....……..... 3

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге….....…….....14

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы белән үзара хезмәттәшлек.....42

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек.....…….…….49

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек .....……...…..52

Эшчәнлектәге хәбәрдарлык …….....……55

2016 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эше турында хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эше турында хисап Татарстан Республикасының 2004 елның 7 июнендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» 37-ЗРТ номерлы Законының 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта Хисап палатасының 2016 елда законнар тарафыннан билгеләнгән бурыч һәм вәкаләтләрне үтәү буенча эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителгән.

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

2016 елда Татарстан Республикасы бюджетын һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетын (алга таба текст буенча – Татарстан Республикасы ММИ территориаль фонды) формалаштыру һәм үтәүне тикшерү кысаларында 113 чара үткәрелде.

Хисап палатасының экспертиза-аналитика эшчәнлегенең төп күрсәткечләре түбәндәге таблицада тәкъдим ителә:

Күрсәткеч атамасы	2012 ел	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
Үткәрелгән экспертиза-аналитика чараларының гомуми саны	108	115	108	107	113
Әзерләнгән экспертиза бәяләмәләре	43	68	57	70	80
Әзерләнгән методик документлар	4	8	3	3	2

2014-2016 елларда үткәрелгән чаралар динамикасы 1 нче диаграммада тәкъдим ителә.

1нче диаграмма

Үткәрелгән чаралар нәтиҗәләре буенча 80 бәяләмә әзерләнгән, шул исәптән:

- Татарстан Республикасы законнары проектларына 31 бәяләмә;

- «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын көйләү» дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына 3 бәяләмә;

- 2016 елның 1 кварталында, 1 яртыеллыгында һәм 9 ае эчендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында 6 бәяләмә;

- 2015 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча 62 бәяләмә;

- 2015 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты чараларын төп кулланучыларның еллык бюджет хисаплылыгын тикшерү нәтиҗәләре буенча 37 бәяләмә;

- «2016-2020 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртә торган тармакларын үстерү» Татарстан Республикасының дәүләт программасы кысаларында Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына

сәнәгатьтәге инвестициялә̆ү проектларны тормышка ашыруга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектына бәяләмә.

Законнар проектларына һәм Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында бәяләмәләр –Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, дәүләт программасына үзгәрешләр кертү проектларына һәм карарлар проектына бәяләмәләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына билгеләнгән вакыт аралыгында тәкъдим ителде.

Хисап елында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Хисап палатасына җибәрелгән 31 закон проекты буенча экспертизалар үткәрелде һәм бәяләмәләр әззерләнде (1 нче таблица).

1 нче таблица

Атамасы	Саны (берәмлек)
Экспертиза бәяләмәсе әзерләнде, барлыгы шул исәптән:	**31**
- 2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар вакыт аралыгына ТР бюджеты һәм ТР ММИ Территориаль фонды бюджеты турында законнар проектларына	2
- 2015 ел өчен ТР бюджеты һәм ТР ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында законнар проектларына	2
- 2016 елга ТР бюджеты һәм ТР ММИ Территориаль фонды бюджеты турында законнарга үзгәрешләр кертү турында законнар проектларына	5
- ТР законнарының башка проектларына	22

«2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына экспертиза үткәрү барышында закон проектының бюджет законнарына туры килүе мәсьәләләре каралды, закон проекты белән бер үк вакытта тәкъдим ителгән документлар һәм исәп-хисапларга анализ үткәрелде.

Экспертиза йомгаклары буенча республиканың 2017-2019 елларга бюджеты проектында баланс саклануы билгеләп үтелде. Татарстан Республикасының 2017-2019 елларга бюджет дефициты күләмнәре бюджет законнарында билгеләнгән чикләрдән артып китми.

2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакытына республика бюджеты проектын төзегәндә нигез итеп алынган төп макроикътисадый күрсәткечләр фаразы федераль дәрәҗәдә база вариантының сценар шартларын истә тотып формалаштырган. Тышкы икътисадый коньюнктураның һәм дөнья икътисадының торышының мөмкин булган үзгәрешләре, шулай ук тышкы сәяси куркынычлар макроикътисадый күрсәткечләрнең динамикасы характерына йогынты ясарга мөмкин.

2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакытына бюджет проекты федераль бюджет, Россия Федерациясе Пенсия фонды, Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды дәүләт корпорациясе чараларының регионнар буенча бүленеше булмаган шартларда төзелде. Шуңа бәйле рәвештә 2017-2019 елларга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре һәм чыгымнары күрсәткечләре күрсәтелгән чараларның Россия Федерациясе субъектлары буенча бүленүе барышында тәгаенләнәчәкләр.

2017 елга бюджет чыгымнарында Татарстан Республикасының 30 дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга чаралар карала. Бәяләмәдә республика бюджетын раслаганнан соң, 2017 елга бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен исәпкә алып, 24 дәүләт программасы буенча параметрларны тәгаенләү таләп ителәчәге билгеләп үтелә.

Экспертиза кысаларында ачык норматив йөкләмәләр үтәлешенә бюджет ассигнованиеләре күләмнәренә (2017 елга – 13 956,1 млн. сум, 2018 елга – 14 583,8 млн. сум, 2019 елга – 15 171,1 млн. сум) анализ ясалды. Бюджет проектының экспертиза нәтиҗәләре республика Хисап палатасы бәяләмәсендә чагылыш тапты.

«2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе Территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча закон проектының законнар таләпләрен истә тотып төзелүе, керемнәр күләмнәре һәм аның дефицитын финанслау чыганакларыннан килгән керемнәрнең чыгымнар күләменә туры килүе, бюджет дефициты күләмнәренең бюджет законнары белән билгеләнгән чикләрдән артып китмәгәнлеге билгеләп үтелә.

Хисап чорында **«2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында**

законнарның 3 проектына һәм **«2016 елга Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында** законнарның 2 проектына экспертизалар үткәрелде. Экспертиза нәтиҗәләре буенча закон проектларының гамәлдәге законнар таләпләренә туры килүе һәм кертелә торган үзгәрешләрнең нигезле булуы турында нәтиҗә ясалды.

Татарстан Республикасының **«2015 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында»** һәм **Татарстан Республикасының «2015 елга Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында»** законнары проектларына экспертиза үткәрү нәтиҗәләре буенча закон проектлары күрсәткечләренең Хисап палатасының тышкы яктан тикшерүен үткән Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисаплар күрсәткечләренә туры килүе расланды. Бәяләмәләрдә Законнар проектлары һәм аларның кушымталары составлары һәм эчтәлекләре буенча бюджет законнары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирүләре билгеләп үтелде.

«Татарстан Республикасы халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» законы проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча тәкъдим ителә торган үзгәрешләрнең социаль ярдәм күрсәтүнең аерым чараларын алучылар санының динамикасына һәм агымдагы елдагы республика бюджеты чыгымнарының күләме аны бирүгә йогынты ясарга мөмкинлеге билгеләп үтелде. Экспертиза нәтиҗәләре буенча Хисап палатасы Бәяләмәсе Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим ителде.

«Физик тәрбия һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» закон проектына Хисап палатасының бәяләмәсендә республиканың чыгым йөкләмәләре исемлеген «Хезмәткә һәм оборонага әзер» Бөтенроссия физик тәрбия-сәламәтләндерү комплексын тормышка ашыру өчен шартлар белән тәэмин итү өчен йөкләмә белән тулыландырырга тәкъдим ителүе билгеләп үтелә, бу исә алга таба аны финанслау чыганакларын ачыклауны таләп итәчәк.

«Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана торган салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкалары билгеләү турында» Татарстан Республикасы законының 2 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү турында», «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы законының 2 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләр) территорияләрендә төзелгән алдынгы социаль-икътисадый үсеш территорияләрендәге резидентлар өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында», «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында», «2017 елга Татарстан Республикасында муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркемнең хәле җитәрлек һәм бушлай мәктәпкәчә белем алуга хокукларын тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итүнең нормативларын раслау турында», «2017 елга Татарстан Республикасының муниципаль мәктәпкәчә гомуми белем бирү оешмаларында һәркемнең хәле җитәрлек һәм бушлай мәктәпкәчә белем алуга хокукларын тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итүнең нормативларын раслау турында», «2017 елга Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркемнең хәле җитәрлек һәм бушлай мәктәпкәчә, гомуми башлангыч, гомуми төп, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларын тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итүнең нормативларын раслау турында», «Татарстан Республикасында тәртип саклауның җәмәгать пунктлары турында» Татарстан Республикасы Законының 5 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында», «Беренче тапкыр шәхси эшмәкәр буларак теркәлгән һәм салым салуның гадиләштерелгән системасына һәм (яки) салым салуның патентлы системасына күчкән салым түләүчеләр өчен салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55^2 маддәсенә үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрен гамәлдән чыгару турында», «2017 елга Татарстан Республикасы хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында», «Россия Федерациясендә

халыкның финанс грамоталылыгы дәрәҗәсен күтәрүгә һәм финанс белем бирүне үстерүгә ярдәм итү» Проектын тормышка ашыру турында килешүне раслау турында», «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында», «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 55 маддәсенең 2 пунктындагы дүртенче абзацының юридик көчен туктату турында», шулай ук «Татарстан Республикасында 2015 ел салым вакыт аралыгы өчен түләргә тиеш булган физик затлар милкенә салым буенча түләнми калган өлеше күләменә пеня өстәп яза башлау вакытын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законнары проектлары эчтәлегенә искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булмады.

Хисап елында **«2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чималы һәм азык-төлек базарларын көйләү»** дәүләт программасына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 3 карарына экспертиза үткәрелде.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча дәүләт программасын тормышка ашыру барышын тикшерүне тормышка ашыру өчен шартларны тәэмин итү максатында финанслауның билгеләнә торган күләмнәреннән чыгып, бәяләү индикаторларының кыйммәтләрен тәгаенләргә *(15.02.2016, 26.08.2016, 25.10.2016 көннәрендә кертелгән үзгәрешләр)*, яңадан кертелгән аерым программа чаралары буенча – программаны тормышка ашыруны бәяләү индикаторларын билгеләргә *(26.08.2016 һәм 25.10.2016 көннәрендә кертелгән үзгәрешләр)*, аларның эчтәлегенә карата билгеләп куелган таләпләрне истә тоткан хәлдә, тәкъдим ителгән проектларны эшләп бетерергә, шул исәптән «Иҗтимагый инфраструктура объектларына капитал кертемнәре» проектын *(26.08.2016 һәм 25.10.2016 көннәрендә керткән үзгәрешләр)* чарасы буенча мәгълүматны детальләр буенча күрсәтергә тәкъдим ителде. Хисап палатасы тәкъдимнәре нигездә дәүләт программасын эшләп бетергәндә һәм үзгәрешләрне раслаган чакта исәпкә алынды.

«2016-2020 елларга Татарстан Республикасы сәнәгатенең эшкәртү тармакларын үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында сәнәгатьтә инвестиция проектларын тормышка ашыруга чыгымнарның бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы предприятиеләренә һәм оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан

Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектына бәяләмәдә карар проектының закон таләпләренә туры килүе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 15 мартында кабул ителгән «Сәнәгать предприятиеләрен модернизацияләү һәм үстерү буенча инвестиция проектларын тормышка ашыруга тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау буенча чыгымнарны финанслауда катнашуга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 194 номерлы карары нигезләмәләренә каршы килмәве билгеләп үтелә.

Хисап елында **республика бюджетының агымдагы үтәлешен** тикшерү кысалырында квартал саен Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджетының керемнәр килү һәм тотылган чыгымнар күрсәткечләренә күләмнәре һәм төзелеше, бюджетлар дефицитын каплауга җәлеп ителә торган чараларның чыганаклары һәм күләмнәре буенча анализ ясалып торды.

Шулай ук Татарстан Республикасының ачык норматив йөкләмәләрен, дәүләт программаларын үтәүгә, республика бюджеты чыгымнары үтәлешенең, республика муниципаль берәмлекләре бюджетларына трансфертлар бирүнең үз вакытында булуы һәм түлылыгы мәсьәләләре дә каралды. Дәүләт бурычы һәм аңа хезмәт күрсәтүгә чыгымнар торышына, Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән кредитлар буенча бурычлар торышына мониторинг уздырылды.

Бюджет үтәлешенә, керемнәр килүе һәм тотылган чыгымнар күрсәткечләрен, бюджет дефицитын финанслау чыганакларыннан алынган чаралар күләмнәрен, республика дәүләт бурычы торышының закон тарафыннан расланган күрсәткечләр белән чагыштырмадагы нәтиҗәләрен, күрсәткечләрнең алдагы елның шундый ук күрсәткечләренә карата динамикасын анализлау нәтиҗәләре квартал саен Хисап палатасы бәяләмәләрендә чагылыш тапты.

Хисап чорында 2014 һәм 2015 елларда **Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру барышына мониторинг** үткәрелде, аның кысаларында дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү, максатчан индикаторларга ирешү, дәүләт программаларын тормышка ашыру

барышы турындагы хисапларның тулылыгы һәм дөреслеге мәсьәләләре каралды.

Мониторинг барышында бюджет ассигнованиеләре белән нәтиҗәләр арасында үзара төгәл бәйләнеш булмавы турында сөйли торган, дәүләт программаларының индикаторларын (күрсәткечләрен) планлаштыруның җитәрлек дәрәҗәдә сыйфатлы булмавына күрсәтә торган фактлар ачыкланды: аерым чаралар буенча финанслау күләмнәре үзгәргән очракта бәяләү күрсәткечләре тәгаенләнмәгән. Аерым очракларда финанслау күләмнәре үзгәрмәгән чакта индикаторлар сизелерлек дәрәҗәдә арттырып башкарылган.

Аерым дәүләт программалары буенча хисапларда тотылган чыгымнар күрсәткечләре законнар белән расланган күрсәткечләргә туры килми, анализлан торган вакыт аралыгында планлаштырылган һәм финансланган программа чараларының кайберләре буенча индикаторларга ирешү турында мәгълүмат булмады. Шулай ук хисапларда дәүләт программаларында каралмаган чараларны чагылдыру фактлары да ачыкланды.

Шундый хәлләр ел саен Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тәкъдим ителә һәм бюджет законнары нигезендә программа чараларын һәм бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен тәгаенләү турында карарлар кабул иткәндә кулланыла торган дәүләт программаларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәләрен бозу куркынычын тудыралар.

Мониторинг нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә тәкъдимнәр, шул исәптән дәүләт программаларын тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын билгеләү, дәүләт программасын тормышка ашыру турында хисап формасын тәгаенләү буенча да тәкъдимнәр җибәрелде, алар алдагы эштә исәпкә алынды.

Бюджет законнары нигезендә хисап елында **2015 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында Хисапка** тышкы яктан тикшерү үткәрелде.

Республика бюджетының үтәлеше турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын бәяләү өчен республика бюджет чараларының 41 төп кулланучысының бюджет хисаплылыгы тикшерелде.

Татарстан Республикасы Бюджет кодексында билгеләнгән еллык бюджет хисапларын тапшыру вакытлары бозылуга бәйле рәвештә, административ

хокук бозу турында өч беркетмә төзелгән. Гаепле вазыйфаи затларга карата суд тарафыннан карарлар чыгарылган.

Тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасының 2015 ел өчен бюджет үтәлеше турында Хисапның, аның белән бер үк вакытта тапшырыла торган документларның, бюджет чараларының төп администраторларының еллык бюджет хисапларының билгеләнгән таләпләрне истә тотып төзелүе һәм 2015 елга кабул ителгән бюджет классификациясе кодлары буенча формалаштырылуы ачыкланды.

Татарстан Республикасының 2015 ел өчен бюджет үтәлеше турында Хисап күрсәткечләре бюджет чараларының төп администраторларының еллык бюджет хисаплары мәгълүматлары белән раслана. 2015 ел өчен республика бюджеты үтәлеше турында Хисап күрсәткечләренең законнар тарафыннан расланган күрсәткечләрдән тайпылышлары объектив характерда, аларның барлыкка килү сәбәпләре бюджет законнары тарафыннан билгеләнгән сәбәпләргә туры килә.

Бюджет үтәлеше турында еллык Хисапны тышкы яктан тикшерү кысаларында бюджет үтәлешенә йогынты ясаган төп факторларга анализ, республика дәүләт программалары чараларын тормышка ашыруга бюджет чыгымнарын башкаруга, муниципаль берәмлекләр бюджетларына трансфертлар бирүгә, бюджет дефицитын финанслау чыганакларыннан чаралар җәлеп итүгә, республика дәүләт бурычы торышына анализ үткәрелде.

2015 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында Хисапны тышкы яктан тикшерү нәтиҗәләре буенча 2015 ел өчен еллык хисапта Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында мәгълүматларның дөрес һәм тулы булмаган фактлары булуы ачыкланмады.

2011 елның 7 февралендә кабул ителгән «Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнарын оештыру һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 6-ФЗ номерлы Федераль законын, Татарстан Республикасының 2004 елның 7 июнендә кабул ителгән 37-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» законын тормышка ашыру кысаларында 2016 елда түбәндәгеләр эшләнде һәм расланды:

- тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандарты: «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тикшерү»;

- «Татарстан Республикасы дәүләт программаларын тормышка ашыру барышын тикшерү» буенча методик тәкъдимнәр.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

2016 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең аерым мәсьәләләре буенча 13 министрлыкта һәм ведомствода, 19 муниципаль районда, шулай ук республиканың аерым учреждениеләре һәм оешмаларында тикшерү чаралары үткәрелде. Барлыгы 494 объект тикшерелде.

Хисап палатасының тикшерү-ревизия эшчәнлегенең төп күрсәткечләре таблицада китерелә:

Күрсәткеч атамасы	2012 ел	2013 ел	2014 ел	2015 ел	2016 ел
I. Тикшерү-ревизия эшчәнлеге					
Үткәрелгән тикшерү-ревизия чараларының саны	53	53	54	53	53
Тикшерү-ревизия чаралары үткәргәндә җәлеп ителгән объектлар саны (берәмлек)	483	487	491	489	494
Бозуларның ачыкланган күләме (мең сумнарда)	3 043 991,9	2 615 511,7	2 349 977,6	2 323 779,1	1 563 950,8
II. Тикшерү чаралары нәтиҗәләрен тормышка ашыру					
Чаралар бюджетка кайтарылган һәм чаралар күрелгән (мең сумнарда)	2 530 004,3	2 303 355,3	2 150 982,7	2 056 006,2	1 363 516,6
Тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча прокуратура һәм хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны (берәмлек)	58	61	54	53	53
Хисап палатасы тикшерүләре материаллары буенча суд һәм башка вәкаләтле органнар тарафыннан административ җаваплылыкка тарту турында кабул ителгән карарлар саны	33	34	40	66	98
Хисап палатасы материаллары буенча кузгатылган җинаять эшләре саны	4	9	2	2	5

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәләре буенча 2011-2015 еллар һәм 2016 елның узган вакыт аралыгы өчен социаль-мәдәни һәм күпфункцияле үзәкләр (авыл клублары) төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлауга бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны, 2015 елда мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре биналары төзелеше буенча эшләр башкаруга киткән чыгымнарның артуы белән бәйле булган аерым мәсьәләләрне тикшерүләр үткәрелде, 2013-2015 елларда муниципаль берәмлекләрдә социаль объектлар төзелеше вакытында бәяләрнең типовой нормативларын һәм мәйданнарны билгеләүне саклау анализланды.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы һөнәри белем бирү буенча мәгариф оешмаларына бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит һәм гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән чараларны файдалануны тикшерү үткәрелде.

Хисап палатасы (эксперт төркеме составында) Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе белән берлектә Алексеевский, Биектау һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарында коррупциягә каршы чараларны тормышка ашыруда гамәли ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар, шулай ук «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» Дәүләт казна учреждениесендә, ««Жилсервис» Идарә компаниясе» ҖЧҖ, «Осиново инженерлык челтәрләре» ААҖ, «Камаз» футбол клубы» ҖЧҖ, «Алкоторг» ҖЧҖ, «Вамин Татарстан» ААҖдә аерым мәсьәләләр буенча тикшерүләр уздыруда катнашты.

Татарстан транспорт прокуратурасы мөрәҗәгате буенча пассажирларны шәһәр яны тимер юл транспорты белән йөртүне башкара торган компанияләр эшчәнлегендә бюджет законнарының саклануы тикшерелде.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы белән берлектә 2014-2015 елларда һәм 2016 елның узган вакыт аралыгында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларының, шулай ук резерв һәм башка төр фондларның бюджеттан тыш фондлары чараларын формалаштыру һәм тотуны тикшерү үткәрелде.

Татарстан Республикасында Террорчылык һәм экстремизмны кисәтү мәсьәләләре буенча ведомствоара эшче төркем каршындагы эксперт төркеме

составында Хисап палатасы Сарман һәм Әлмәт муниципаль районнарында террорчылыкка каршы тору өлкәсендә законнарны үтәү белән бәйле мәсьәләләр буенча тикшерүләр уздыруда катнашты.

2016 елда **53** тикшерү-ревизия чарасы үткәрелде, гомуми күләме **1 563 950,8 мең сум** булган бюджет чараларын һәм милкен куллануда бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды, шул исәптән:

- дәүләт (муниципаль) милек белән идарә итү һәм файдалану вакытында бозулар – **1 041 329,8 мең сум;**
- бюджетларны формалаштыру һәм үтәү вакытында бозулар – **350 332,7 мең сум;**
- дәүләт һәм муниципаль хаҗәтләр өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендәге бозулар – **118 564,3 мең сум;**
- башка төр бозулар (субсидия алучылар тарафыннан үз хисапларын тапшырмау, бюджет законнарын башка төр бозулар) – **53 724,0 мең сум.**

2016 елдан башлап тикшерү чаралары үткәргән вакытта Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы тарафыннан яңа редакциядә хупланган Тышкы дәүләт аудиты (тикшерүе) барышында ачыклана торган бозулар классификаторы кулланыла. Аның нигезендә бюджет чараларын нәтиҗәсез куллану, бухгалтерлык исәп-хисабын һәм хисаплылыгын бозулар һәм тагын башка бозулар акчалата рәвештә исәпкә алынмаган, бу 2015 ел белән чагыштырганда аерым йомгаклау күрсәткечләренең кимүенә шактый зур йогынты ясаган.

Хисап елында гомуми күләме 3 469,0 мең сум булган бюджет чараларының нәтиҗәсез файдаланылу ачыкланды.

2016 елда үткәрелгән тикшерү чаралары барышында Татарстан Республикасы Хисап палатасы ачыклаган финанс бозулары төзелеше

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтүгә җибәрелгән бюджет чараларын куллануның **нәтиҗәлелегенә үткәрелгән аудит** нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына дәүләт ярдәме күрсәтү буенча эзлекле эш алып барылуы билгеләп үтелә. Республика федераль бюджет чараларын бирү буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы уздыра торган бәйгеләрдә уңышлы катнаша.

Шул ук вакытта әлеге өлкәдә дәүләт чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру резервлары ачыкланды. Сайлап тикшерү тарафыннан Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына субсидияләрне максатчан файдалану, бизнес-проектларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелегенең планлы күрсәткечләренә ирешү турында хисапларның үз вакытында бирелмәүнең, хисап мәгълүматларын бозып күрсәтүнең аерым очраклары ачыкланды.

Инжинирингның региональ үзәкләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру резервлары билгеләнде.

Эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруда катнаша торган «Кече эшмәкәрлек лизинг компаниясе» ҖЧҖн тикшерү барышында лизинг түләүләре буенча тикшерү вакытына бурыч күләме 86,6 млн. сум тәшкил итүе ачыкланды. Калдык бәясе 112,5 млн сумлык җиһазлар, техника һәм башка милек алынды.

Лизинг компаниясе милкендә файдаланылмый торган Яшел Үзән шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 36 йорт адресы буенча урнашкан 174 млн. сумлык 4 катлы автомат телефон станциясе бинасы тора. Бина начар хәлдә: тәрәзәләрнең күп өлеше юк яисә ватык, түбәсеннән яңгыр үтә. Тикшерү вакытында түбә япмасы киредән торгызылды.

Яшел Үзән шәһәре, Төзүчеләр проспекты, 36 йорт адресы буенча урнашкан файдаланылмый торган автомат телефон станциясе бинасы

Үткәрелгән аудит йомгаклары буенча дәүләт ярдәме күрсәтү чараларын тормышка ашыруны норматив хокукый яктан тәэмин итүне камилләштерү, эчке финанс тикшерүен көчәйтү, куркынычлар белән идарә итү системасын куллану, мониторингны тормышка ашыру вакытында мәгълүмати технологияләрне куллану буенча тәкъдимнәр әзерләнде.

Бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә аудит нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Җиһазлар алу вакытында аффиляцияләнгән структуралар аша ярдәм күрсәтү чараларын үзләштерү куркынычын булдырмау максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү һәм ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга вәкаләтле булган «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» ДКУ нең 2016 елның 18 апреледә кул куелган 20 номерлы боерыгы белән расланган Субсидиягә гариза бирүчеләр, тәэмин

итүчеләр һәм алучыларның бәйлелек (аффиляциялелек) мөнәсәбәтләре барлыгын тикшерү регламенты эшләнде.

Аудит йомгаклары буенча әзерләнгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының: 2016 елның 1 августында кул куелган – 530 номерлы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү» дәүләт мәгълүмати-аналитика системасын булдыру һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чараларының нәтиҗәлелеге мониторингы турында», 2016 елның 11 июлендә кул куелган 470 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 19 июнендә кул куелган 416 номерлы карары белән расланган Субсидияләр рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» карарлары кабул ителде.

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына субсидияләрне максатчан файдалану турында хисапларын үз вакытында бирмәү очраклары буенча 3 физик һәм 4 юридик зат гомуми күләме 105 мең сум булган штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылганнар.

2011-2014 еллар һәм 2016 елның 9 ае өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм аның ведомствосына караган учреждениеләрнең **энергетика ресурсларыннан файдаланганда** Татарстан Республикасы һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте фонды **бюджетлары чараларын тотуының нәтиҗәлелегенә карата үткәрелгән аудит** нәтиҗәләре буенча Министрлыкның энергияне артык куллануны киметү буенча билгеле бер чаралар күрелүе билгеләп үтелде. Энергия ресурсларын тотуның тармак буенча тулаем алганда тикшерелгән вакыт аралыгында тотрыклы кимү динамикасы бар.

Шуның белән бергә уздырылган аудит энергия куллану һәм энергия ресурслары нәтиҗәлелеге өлкәсендә аерым кимчелекләр һәм резервларны ачыклады. Мәсәлән, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә медицина хезмәтләренә тарифлар формалаштыру энергетик тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыклана торган учреждениеләрнең энергия ресурсларында норматив хаҗәтен исәпкә алмыйча эшләнгән.

Министрлыкта эшләп килгән энергия саклау белән идарә итү системасы нәтиҗәлелекне бәяләү һәм мониторинг механизмын оптимизацияләү индикаторларын төзәтү өлешендә актуальләштерүне таләп итә.

Сәламәтлек саклау учреждениеләренең гамәли эшчәнлегендә энергетик тикшерүләр нәтиҗәләре тулы күләмдә файдаланылмый, алынган энергетика җиһазларыннан файдалануны исәпкә алу һәм тикшерү тәэмин ителми.

Мәсәлән, «Республика клиник неврология үзәге» ДАССУдә гомуми бәясе 2 495,3 мең сум булган энергетика җиһазлары (җылыту казаннары) 2008 елның августыннан бирле файдаланылмаган.

«Республика клиник неврология үзәге» ДАССУдә файдаланылмый торган җиһазлар

Моннаан тыш, 2011 елның 6 декабрендә кул куелган «Бухгалтерлык исәбенә алу турында» 402-ФЗ номерлы Федераль законын бозып, учреждениеләрдә гомуми күләме 37 587,3 мең сум булган төп чаралар үз вакытында (2013 елдан башлап) бухгалтерлык исәбенә алынмаганнар. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 20 сәламәтлек саклау учреждениесендә гомуми бәясе 33 851,9 мең сум булган куелган җиһазлар бухгалтерлык исәбендә чагылыш тапмаган.

Җибәрелгән бозулар һәм җитешсезлекләр өчен сәламәтлек саклау учреждениеләренең 2 вазыйфаи затына карата административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде.

Аудит нәтиҗәләре буенча әзерләнгән, энергетика ресурсларын кулланның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән тәкъдимнәр һәм кисәтүләр Эксперт советы тарафыннан хупланды.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары турында хисап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде

Үткәрелгән нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары буенча Министрлык 2016 елның 1 июнендә кул куелган «Энергоресурсларны кулланган вакытта финанс чараларын тоту турында» 1181 номерлы боерыгын чыгарды. «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина учреждениеләрендә энергоресурсларны файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү буенча нигезләмә»не (алга таба – Положение) эшләп бетерелде, «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү белән идарә» ДБУ белән килешенде һәм расланды.

2017 елдан коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бюджет ассигнованиеләрен планлаштыру алдагы вакыт аралыгында гамәлдә кулланылган бәядән чыгып һәм чагыштырмача соңгы чик булган кыйммәтләр буенча 2010 ел дәрәҗәсеннән 15%ка киметү белән, энергоресурслар кулануны мәҗбүр киметү белән карала. Министрлык карамагындагы учреждениеләргә энергоресурсларның чагыштырмача чыгымнарын энергетика паспортларының норматив мәгълүматларына, алар булмаган очракта – Нигезләмәнең соңгы чик кыйммәтләренә туры китерүне тәэмин итү йөкләнелә.

Министрлык сәламәтлек саклау учреждениеләрен реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне, энергия саклау мәсьәләләрен исәпкә алып, аерым тикшерүгә алды.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында булган **һөнәри белем бирү оешмаларына** бүлеп бирелгән дәүләт чараларын файдалануның нәтиҗәлелегенә үткәрелгән аудит йомгаклары буенча Татарстан Республикасында һөнәри белем бирү системасын үстерүгә зур игътибар бирелүе, аның матди-техник базасын яхшыртуга шактый күләмдә финанс һәм матди ресурслар тотылуы ачыкланды.

2014 елдан башлап ел саен республика икътисадының кадрлар ресурсларына карата ихтыяҗы бәяләнә һәм югары һәм махсус һөнәри белемле кадрлар әзерләүгә Татарстан Республикасы дәүләт заказы булдырыла. Татарстан Республикасы икътисадын үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган Таләп ителә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр исемлеге раслана.

Ресурс үзәкләре булдыру, Татарстан Республикасы һөнәри белем бирү учреждениеләренең «WorldSkills Russia» хәрәкәтендә актив катнашуы республика һөнәри белем бирү системасының халыкара стандартлар нигезендә үсүенә, урта белем бирү учреждениеләре укучылары өчен һөнәри белем бирүнең әһәмиятен күтәрүгә ярдәм итә.

Шуның белән бергә уздырылган аудит һөнәри белем бирү өлкәсендә аерым җитешсезлекләр һәм резервлар булуны да ачыклады.

Аерым белгечлекләр буенча уку йортларын тәмамлаучылар санының эш бирүчеләр таләпләренә туры килмәве һөнәри белем бирү учреждениеләрен тәмамлаучыларны яңадан әзерләү зарурлыгына китерде.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм тармак министрлыклары тарафыннан кирәк булган белгечлекләрдә ихтыяҗ предметына икътисадның реаль секторы субъектларының мониторингы җитәрлек дәрәҗәдә үткәрелмәгән.

Һөнәри белем бирү учреждениеләре укытучылары һәм производствога өйрәтү осталарының хезмәтенә түләүнең түбән дәрәҗәсе һөнәри белем бирүнең сыйфатын күтәрүгә ярдәм итмәде.

Һөнәри белем бирү учреждениеләрендә тикшерүләр барышында аерым бозулар һәм кимчелекләр ачыкланды.

Дәүләт йөкләмәсен үтәүне (6 учреждение биналарын җылыту буенча) финанс белән тәэмин итүгә субсидияләр күләмен гомуми күләме 11 023,9 мең сумга арттыру фактлары билгеләнде. Шулай, Кече бизнес һәм эшмәкәрлек көллиятендә (Казан шәһәре) әлеге чараларның күләме 2014 елда 3 468,4 мең сумга, 2015 елда 137,9 мең сумга арттырыла.

Дәүләт милке белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә дә бозулар бар. Шулай, А.П. Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумында гомуми бәясе 16 961,4 мең сум булган ашханә, уку корпусы, механик остаханәләр, гараж файдаланылмый.

А.П. Обыденнов исемендәге Казан автотранспорт техникумында файдаланылмый торган милек һәм төп чаралар

П.В. Дементьев исемендәге Казан авиация-механика көллиятендә уку бинасы максат буенча файдаланылмый. Шул ук вакытта 2014-2016 елларда аңа гомуми күләме 13 054,1 мең сум булган реконструкция үткәрелгән. Шуның белән бергә, уку бинасы капиталь төзелеш объектын реконструкцияләү вакытында җибәрелгән бозулар сәбәбе буенча файдаланылмый, бу Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе боерыгы тарафыннан раслана.

Аудит нәтиҗәләре буенча республика һөнәри белем бирү системасын үстерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерләнде.

Нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары турында хисап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

2013-2016 елларга **кан тамырлары авырулары белән чирләгән авыруларга махсуслаштырылган медицина** ярдәме, шулай ук ашыгыч ярдәм, медицина эвакуациясе күрсәтү буенча чаралар үтәлешенең нәтиҗәлелегенә аудит 2020 елга кадәр Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклауны үстерү программасын (алга таба – Программа) тормышка ашыруны бәяләү индикаторларының өстәмә ихтыяҗны финанслауны истә тотып билгеләнгәнлеге, ләкин аның чыганагы ачыкланмаганлыгын күрсәтте. Шулай итеп, өстәмә ихтыяҗны финанслау булмаганда яисә җитәрлек булмаганда, планлаштырылган чараларның үтәлмәү һәм 2020 елга Программаның планлаштырыла торган максатлары һәм бурычларына ирешмәү куркынычы бар.

Программаның аерым күрсәткечләренә өлешчә ирешелгән. Мәсәлән, планлаштырылган 100 мең кешегә 210,6 күләмендә һәм шуңа туры китереп 86,4% «Халыкның цереброваскуляр авырулардан үлеме» һәм «Ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының авыру янына 20 минуттан да азрак вакыт эчендә барып җитү өлеше» юнәлешләренең максатчан кыйммәтләре гамәлдә 100 мең кешегә 242,9 һәм 85,9% тәшкил итте.

Сәламәтлек саклауның төп ресурсларының берсе булып кадрлар потенциалы тора, чөнки аның торышына халыкка медицина ярдәме күрсәтү мәсьәләләрен чишүнең перспективалары бәйле. Кадрлар белән тәэмин итүнең

тиешле дәрәҗәдә булмавы турында ике урында эшләүнең югары коэффициенты сөйли: табиблар арасында ул уртача 1,7, ә аерым очракларда 3,0 кә җитә.

Шулай, Чистай ҮРХнең баш миендәге кан әйләнеше кискен бозылган авырулар өчен аталган бүлегендә 2016 ел башына штат буенча 22,5 ставка табиблар каралган, чынбарлыкта 3 белгеч эшли.

Тикшерелгән учреждениеләрдә төзек булмаулары сәбәпле югары технологияле җиһазларның тик тору фактлары ачыклана. Шулай, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» ДАССУда Signa HD магнит-резонанслы томограф 2015 елда 102 көн, 2016 елның 5 ае эчендә 80 көн эшләмәгән. «Яр Чаллы шәһәренең 5 номерлы шәһәр хастаханәсе» ДАССУда Phillips Brillians компьютерлы томограф 2014-2015 елларда 174 көн тик торган. Сәламәтлек саклау учреждениеләренең җиһазларга ремонт ясату өчен чаралары җитәрлек түгел, шуның белән бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан өстәмә финанслау бүлеп бирелә.

Нәтиҗәлелек аудиты барышында республика кан тамырлары үзәкләрендәге авырулар арасында социологик сораштыру үткәрелде. Әлеге сораштыру пациентларның бушлай медицина ярдәме күрсәтү өлкәсендә үз хокуклары турында мәгълүматларының югары булмавын күрсәтте. Сораштыруда катнашучыларның яртысы диярлек (48%) бушлай медицина ярдәменең төрләре турында белмиләр, авыруларның 24%ы стационарда дәвалану вакытында билгеләнгән медикаментларны үзләре сатып алганнар.

Медицина хезмәте күрсәтү өлкәсендәге актуаль проблемалар арасында респондентлар шулай ук дару препаратларының кыймммәт булуын (сораштыручыларның 35 %ы), түләүле медицина ярдәменең күләме артуын (22%) билгеләп үттеләр.

Аудит нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Программаны тормышка ашыруга җибәрелгән дәүләт чараларын куллануның нәтиҗәлелеген күтәрү буенча чаралар күрергә, билгеләнгән куркынычларны анализларга, аларны минимизацияләүгә һәм

соңгы нәтиҗәләргә ирешүнең гарантияле булуы дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән төзәтмәләр кертергә тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча 2011-2015 еллар һәм 2016 елның узган вакыт аралыгы өчен **социаль-мәдәни һәм күпфункцияле үзәкләр** (авыл клублары) **төзелешенә, реконструкцияләү һәм капталь ремонтка** бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны, аларны тотуның нәтиҗәлелеген тикшерү үткәрелде.

Тикшерү чарасы Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында, Татарстан Республикасы Төп инвестиция-төзелеш идарәсендә, 181 авыл клубында үткәрелде.

193 торак пунктында яшәүчеләр арасында анкета уздырылды, сораштыруларда катнашучыларның гомуми саны 4 245 кеше тәшкил итте. Социаль тикшеренү сораштырылган респондентларның 91%ы авыл клублары эше белән канәгать булуын, 8,2% – өлешчә канәгатьләндерүен, 0,8% бөтенләй канәгать булмауларын күрсәтте.

Күпфункцияле мәдәни үзәкләр төзелеше программасы Татарстан Республикасында авыл җирлегендә яши торган гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү максатларында тормышка ашырыла торган социаль әһәмияткә ия проектларның берсе булып тора.

Авыл клублары төзелешенә Татарстан Республикасы бюджетыннан 2012-2015 еллар эчендә 2 010 млн. сум чара җибәрелгән, 181 объект төзелгән экономияләнгән 33,6 млн сум акча бюджетка кире кайтарылган.

Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча авыл клублары төзелеше һәм файдалану нәтиҗәлелеген күтәрү буенча 19 тәкъдим әзерләнгән, алар, җаваплы үтәүчеләрне күрсәтеп, тикшерү чарасы нәтиҗәләре турында Хисапта чагылыш тапкан. Аерым алганда, аларның эш графикларын оптимизацияләү, кирәкле җиһазлар һәи инвентарьләр белән җиһазлап бетерү, кадрлар белән тәэмин итүне камилләштерү, авыл клублары базасында спорт чаралары үткәрү практикасын киңәйтү хисабына авыл клублары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү резервлары билгеләнгән.

Төзелгән объектларны эксплуатацияләү барышында аерым техник җитешсезлекләр ачыкланган, алар буенча Татарстан Республикасы Төп инвестиция-төзелеш идарәсе кураторлар, подрядчы оешмалар, балансны тотучылар белән бергә эш оештырган. Нәтиҗәдә күп кимчелекләр юкка чыгарылган, калганнары буенча подрядчы оешмаларның контракт йөкләмәләрен үтәүләре кысаларында гарантия хатлары бирелгән.

Социаль-мәдәни һәм күпфункцияле үзәкләр төзелешенә, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтка бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү материаллары Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы Президиумы утырышында каралды.

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе буенча 2013-2015 елларда һәм 2016 елның узган вакыт аралыгында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә **социаль объектлар төзелешендә бәянең типовой нормативлары саклану һәм мәйданнар билгеләүгә анализ** үткәрелде.

Төзелгән мәктәпләрнең бәясе 1 урынга исәпләгәндә 351,9 мең сумнан алып 964,3мең сумга кадәр булуы билгеләнде. Шулай итеп, Биектау муниципаль районының Биектау авылында 500 укучыга балалар иҗаты үзәге белән гомуми белем бирү мәктәбе төзелешенең смета бәясе 404 063,15 мең сум, ягъни 1 урынга исәпләгәндә 808,1 мең сум тәшкил итә.

2015-2016 елларда яңа төзелгән мәктәпләрнең чынбарлыкта тулылыгы 47%тан (Теләче муниципаль районының Максабаш авылындагы спортзалы белән 15 балага исәпләнгән башлангыч мәктәптә тикшерү вакытына чынбарлыкта 7 укучы иде) 116% ка (Казань шәһәрендәге «Солнечный город» торак комплексы) кадәр тәшкил итте.

Балалар бакчаларында 1 урынны төзүнең уртача бәясе 2013 елда – 868,4 мең сум, 2014 елда – 567,7 мең сум, 2015 елда – 596,1 мең сум тәшкил итте. Мәсәлән, 2013 елда Яшел Үзән муниципаль районының Осиново авылында 53 номерлы «Шатлык» катнаш төрдәге балалар бакчасы

төзелешендә 1 урын бәясе 251,8 мең сум, 2014 елда Казан шәһәренең Идел буе районында 79 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасында 1 урын бәясе – 831,1 мең сум тәшкил итте.

2015-2016 елларда яңа төзелгән балалар бакчаларының чынбарлыкта тулылыгы 22% тан алып 160% кадәр тәшкил итте. Балалар булуның иң түбән күрсәткечләре авыл торак пунктларында 50 урынга төзелгән кечкенә балалар бакчаларына туры килә, мәсәлән, Менделеев районы Брюшли авылындагы «Чишмәкәй» балалар бакчасында – 22%, Тәтеш муниципаль районының Урюм авылындагы «Чишмәкәй» – 28%.

Авыл җирлекләрендә төзелгән социаль объектларның ихыяҗ булу дәрәҗәсе күбесенчә анда яшәүче халык санына бәйле. 2012-2015 елларда 100 кешедән кимрәк булган торак пунктларында Кама Тамагы (Мордва Каратай авылы – 64 кеше, Олы Мәрәтхужа авылы – 82), Чирмешән (Иске Сережкино авылы – 86), Чистай (Булдырь авылы – 60) муниципаль районнарында төзелде.

Яңа социаль объектлар төзү яисә булган биналарга капиталь ремонт турында карар кабул итүнең техник-икътисадый нигезләүнең тәртибе ачыкланмаган. Шулай итеп, 2016 елда Теләче муниципаль районының Үзәк авылында бәясе 12 738,1 мең сум булган яңа авыл мәдәният йорты төзелгән. Шул ук вакытта 1964 елда төзелгән силикат кирпечтән салынган, цинкланган калай түбәле эшләп торучы мәдәният йорты бинасы авария хәлендә булмаган һәм ремонт эшләре башкарган шартларды файдаланырга яраклы хәлдә булган.

Сайлап күчмә тикшерүләр социаль объектның билгеләнгән эш режимын сакламау очрагын ачыклады: Балык Бистәсе муниципаль районының Ямаш авылында авыл клубы шимбә көнне кичке вакытта ябык була (тикшерү вакыты 20:32, шимбә көнне эш режимы: 10:00 дан 13:00 кә кадәр, 19:00 дан 23:00 кадәр).

Үткәрелгән анализ нәтиҗәләре буенча социаль объектларны төзү һәм файдалану вакытында бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләнде.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 6 апрелендә кул куелган 65/о номерлы

боерыгы тарафыннан социаль-мәдәни өлкәсенең объектларына капиталь ремонтка соңгы чик чыгымнарның 2016 елга үлчәү берәмлегенә эш төрләре буенча нормативлары расланды.

Яңа социаль-мәдәният объектлары төзү яисә булган биналарга капиталь ремонт ясау буенча карар кабул итүнең техник-икътисадый яктан нигезләү максатларында, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 25 ноябрендә кул куелган 200/о номерлы боерыгы тарафыннан муниципаль районнар һәм шәһәр округларының социаль-мәдәният өлкә объектларында чынбарлыкта ихтыяҗларын бәяләү системасын эшләү буенча ведомствоара эшче группа төзелде.

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм Сәүдә министрлыгына (алга таба – Министрлык) бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалануны тикшерү дәүләт милкен файдаланган вакытта гомуми күләме 2 423,7 мең сум булган бозуларны ачыклый.

Министрлыкка оператив идарә итү хокукында беркетелгән башлангыч бәясе 2 021 мең сум булган транспорт чарасының (2004 елда чыгарылган HYUNDAI COUNTY автобусы) озак вакыт кирәк булмаганлык очраклары ачыкланды.

Автобусның басып торуы беренчел документларның (юлга чыгу битләре, ягулык-майлау материалларын алу һәм тоту) булмавы белән дәлилләнә. Шул ук вакытта Министрлык төзек булмаган автобус өчен тикшерелә торган вакыт аралыгында транспорт салымы өчен түләү рәвешендә гомуми күләме 12 000 сум булган чыгым тоткан. Бозулар тикшерү вакытында юкка чыгарылган.

Министрлык хезмәткәрләрен кайнар аш белән тукландыруны оештыру өчен ИЭ Еникеева Т.П. белән дәүләт милккен арендалау килешүе төзегән. Килешү шартларын бозып, арендатор коммуналь һәм эксплатация хезмәтләре өчен түләмәгән. Бурыч 257,5 мең сум тәшкил итә.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Министрлыкка ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару өчен күрсәтмә бирелде.

Министрлык тарафыннан арендатор ИЭ Т.П. Еникееваның коммуналь хезмәтләр өчен гомуми күләме 41,7 мең сум булган бурычын түләтү буенча чаралар күрелгән, бурычларын каплау графигы (2016 елның июленнән 2017 елның май аена кадәрле вакыт аралыгы) расланган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын файдалануны тикшерү гомуми күләме 27 608,3 мең сум булган бозуларны, шул исәптән дәүләт милкен файдалану белән бәйле – 25 119,3 мең сумлык бозуларны билгеләде.

Мәсәлән, Хайваннар авырулары белән көрәш буенча республика станциясенең Азнакай, Кукмара һәм Мамадыш муниципаль районнарындагы берләшмәләре тарафыннан гомуми күләме 4 559,5 мең сум булган 14 җиңел автомобильне файдалану яисә үз вакытында гамәлдән чыгару буенча чаралар күрелмәгән.

2013 елда үзәкләштерелгән ягуга күчү сәбәпле, Мамадыш берләшмәсендә гомуми бәясе 2 197,1 мең сум булган котельный 3 елдан артык файдаланылмаган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча котельный бинасын ветлабораториянең биологик калдыкларын яндыру өчен күчерү буенча эш (рөхсәт документларын әзерләү, үзгәртеп җиһазлау) алып барыла.

Идарә аппараты ведомство карамагындагы оешмалар (Казан шәһәренең Ветеринария берләшмәсе, Хайван авырулары белән көрәш буенча станция) балансында саналган гомуми бәясе 4 224,7 мең сум булган 8 берәмлек автотранспорт чарасын законсыз файдаланган. Күрсәтелгән җиңел автомобильләрне тоту өчен ведомство карамагындагы учреждениеләр тарафыннан тикшерелгән вакыт аралыгында 2 478,3 мең сум акча тотылган.

Хайваннар авырулары белән көрәш буенча республика станциясе хисабына тотыла торган Ford Focus Sedan автомобилен чынбарлыкта Идарәнең үзәк аппараты файдаланган

Ведомство карамагындагы шактый учреждениедә булган төп чараларның исәп-хисапта чагылыш тапмавы, аларны гамәлдән чыгару һәм гамәлгә кую буенча операцияләр язылмау фактлары ачыкланган.

Мәсәлән, Казан шәһәренең Ветеринария берләшмәсе тарафыннан гомуми бәясе 6 120,3 мең сум булган 4 ветеринария шифаханәсе һәм 3 административ-хуҗалык корылмасы приходка язып куелмаган.

Хисап палатасы тикшерүе нәтиҗәләре буенча Идарәгә ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрү өчен күрсәтмә бирелде.

Бухгалтерлык исәп-хисабын тупас бозу фактлары буенча ведомство карамагындагы 3 учреждениенең 6 вазыйфаи затына карата административ хокук бозу турында 12 беркетмә төзелде. Вазыйфаи затлар гомуми суммасы 25 мең сум тәшкил иткән штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылды.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын файдалануны тикшерү гомуми бәясе 1 812,8 мең сум булган дәүләт милкен нәтиҗәсез файдалану фактларын ачыклады. Мәсәлән, «Мамадыш урман хуҗалыгы» ДБУ һәм «Бөгелмә урман хуҗалыгы» ДБУнда тикшерү чарасы үткәрелгәнгә кадәр Министрлык 2015 елның ноябрендә сатып алган һәм ведомство карамагындагы учреждениелргә тапшырган 2 төяү гидроманипуляторы файдаланылмаган.

Кулланылмый торган төяү гидроманипуляторы

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан ачыкланган бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрелде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының **Республика клиник онкология диспансеры**» ДАССУна (алга таба – Учреждение) бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджеты чараларын файдалануны тикшерү гомуми бәясе 20 131,7 мең сум булган, шул исәптән дәүләт милкеннән файдаланган вакытта 14 800,6 мең сум күләмендә бозуларны ачыклады.

Тикшерү вакытына булган медицина җиһазлары дәвалау учреждениесен җиһазлау стандартларына тулысынча туры килеп бетми иде.

2016 елның 1 гыйнваренә карата Учреждение балансында 264 берәмлек югары технлолгияле медицина җиһазы (рентген аппаратлары, томографлар, маммографлар һ.б.) тора, шуларның 251 берәмлеге – эшли торган хәлдә. Җиһазларның 77 берәмлеге йөз процентка тузган. Мәсәлән, норматив буенча файдалану вакыты 7 ел булган РУМ-17 рентгенотерапевт аппараты – 22 ел, «Phillips» маммографы – 20 елдан артык вакыт, «Aloka» югары тавышлы сканеры 19 ел дәвамында кулланышта инде.

Бәясе 3 500 мең сум булган КамАЗ 57531 шасси базасындагы күчмә маммография кабинеты, еллык норма 247 эш көне булган вакытта, юлламалар буенча тикшеренүләр уздыру өчен 2014 елда 63 көн, 2015 елда 6 көн чыккан. Аерым очракларда кыйммәтле медицина җиһазы төзек булмау сәбәбе буенча басып торган.

Шулай, бәясе 67 800 мең сум булган «Signa» магнит-резонанслы томограф 2015 елда 139 көн файдаланылмаган. Нәтиҗәдә, 2015 елда уздырылган тикшеренүләр саны, алдагы ел белән чагыштырганда, 2,4 тапкыр кимегән.

КамАЗ 57531 автомобиле базасындагы маммография кабинеты һәм Signa магнит-резонанслы томограф

Медицина җиһазларының (С-Дуга V-25 рентген аппараты, SFX-15 рентген системасы) озак вакыт дәвамында, аерым очракларда 3 елдан артыграк, кирәк булмау фактлары ачыкланды.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Учреждениенең әйдәп баручы хисапчысы һәм әйдәп баручы инженеры дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын файдалануны тикшерү крестьян (фермер) хуҗалыклары башлыкларының билгеләнгән вакытка гомуми бәясе 39,2 млн. сум булган грантлар чараларын куллану турында хисапларын бирмәүләрен ачыклады.

Шулай ук грантлар бирү буенча килешүләрдә билгеләнгән нәтиҗәлелеккә, терлекчелек фермаларын нәселле һәм товарлыклы терлек белән комплектлау, шулай ук даими эш урыннары булдыру буенча планлы күрсәткечләренә тулы күләмдә ирешү тәэмин ителмәгән.

Мәсәлән, «Гаилә терлекчелек фермаларын үстерү» чарасы буенча план билгеләнешләрен үтәү сыерлар – 53%, атлар – 73%, сарыклар башын арттыру өлешендә – 76%, даими эш урыннары булдыру буенча – 94% тәшкил итте.

Гаилә терлекчелек фермалары буенча 480 грант алучының 452 се (ягъни 94%ы) алдан каралган эш урыннары булдырган, яңа эш башлаучы 34 грант алучы, ягъни 26,8%, бер генә эш урыны да булдырмаган.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына – тикшерү чарасы нәтиҗәләре

буенча Хисап, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына ачыкланган бозуларны һәм кимчелекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрү өчен күрсәтмә җибәрелде, тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

Мөслим, Түбән Кама, Азнакай һәм Менделеев муниципаль районнарының аерым крестьян-фермер хуҗалыклары башлыкларына карата гаилә терлекчелек фермаларына ярдәм күрсәтүгә бүлеп бирелгән грантларны файдаланганда караклык гамәлләре кылу фактлары буенча җинаять эшләре кузгатылды.

Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы карамагында булган **психоневрология интернатлары эшчәнлеген тәэмин итүгә** бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджет чараларын файдалануны тикшерү гомуми күләме 26 206,8 мең сум булган финанс бозулары һәм кимчелекләр ачыклаган.

Мәсәлән, Казан, Чистай һәм Яңа Чүриле психоневрология интернатларында озак вакыт (6 елдан 10 елга кадәр) гомуми бәясе 18 894,2 мең сум булган милек – көнкүреш һәм кухня техникасы, җылыту җиһазлары, дизель-генератор, медицина, кер юу җиһазлары, агач эшкәртү һәм токарь станоклары, авыл хуҗалыгы техникасы, хуҗалык корылмалары файдаланылмаган.

Казан һәм Чистай психоневрология интернатларында файдаланылмый торган милек (хуҗалык корылмалары, җиһазлар)

Интернатларда йомшак инвентарь һәм азык-төлек продуктларының аерым төрләре белән тәэмин итүнең нормалары сакланылмаган. Шул ук вакытта продуктларның аерым төрләре (балык, киптерелгән җиләк-җимеш, җиләк-җимеш, кондитер әйберләре) буенча билгеләнгән туклану нормалары

үтәлми, ә икенчеләре (ярма, кузаклылар һәм макарон ризыклары) буенча арттыру күзәтелә.

Бухгалтерлык исәп-хисабын һәм хисапларны алып баруга таләпләрне бозу фактлары буенча психоневрология интернатларының 8 вазыйфаи затына карата административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде, 3 вазыйфаи зат («Чистай психоневрология интернаты» СХДАУ баш хисапчысы, «Тернәкләндерүнең хәзерге заман медицина-социаль технологияләрен кулланып эшли торган Кама аланы психоневрология интернаты» СХДАУ директоры һәм баш хисапчысы) гомуми күләме 6 мең сум тәшкил иткән штраф рәвешендә административ җаваплылыкка тартылдылар.

Татарстан Республикасы муниципаль районнарында уздырылган комплекслы тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча гомуми күләме **768 762,6 мең сум** булган бозулар һәм җитешсезлекләр ачыклана, гомуми күләме 654 344,1 мең сум булган (ачыкланган бозулар күләменең 85,1%ы) бюджет чараларын тоту, республика (муниципаль) милкеннән файдаланган вакытта һәм башка финанс бозулар буенча ачыкланган бозулар һәм җитешсезлекләрне юкка чыгару буенча чаралар күрелгән.

Нурлат муниципаль районында тикшерү тарафыннан муниципаль милек белән идарә итү өлкәсендә 63 395,8 мең сум күләмендә бозулар ачыклана.

Биш авыл җирлегендә (Әмзә, Гәйтән, Якушкино, Киекле һәм Чулпан) гомуми бәясе 4 800 мең сумга сатып алынган тагылма җайланмалары белән «Беларус 82.1» тракторлары җирлекләр бюджетында алардан файдалану өчен чыгымнарны түләүгә чаралар булмау сәбәпле чынбарлыкта файдаланылмыйлар.

Кукмара һәм Нурлат муниципаль районнарында мәгариф учреждениеләре тарафыннан гомуми баланс бәясе 5 041,1 мең сум булган автотранспорт чаралары файдаланылмый, алар өчен 2015 елда гомуми күләме 88,7 мең сум булган транспорт чараларына салым язылган һәм түләнгән.

Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек гимназиясенең файдаланылмый торган 2001 елда чыгарылган ПАЗ-3205 автобусы

Тикшерүләр барышында муниципаль милектә булган объектлар һәм милекнең нәтиҗәсез файдалану очраклары ачыкланды. Шулай, Бөгелмә муниципаль районында гомуми бәясе 6 340 мең сум булган кулланылмый торган күчемсез милек объектларының (административ бина, кеше яшәми торган бүлмәләр, җитештерү базасы) , Чистай муниципаль районында гомуми бәясе 4 876 мең сум булган күчемсез милекнең 14 объекты (административ бина, кеше яшәми торган бүлмәләр, җитештерү базасы), аерым очракларда 3 елдан артык, файдаланылмаганлыгы билгеле булды.

Бөгелмә шәһәре, Октябрь урамы, 4нче йорт адресы буенча урнашкан административ бина

Чистай шәһәре, Ногин урамы, 6 нчыйорт адресы буенча урнашкан административ бина

Апас муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасын тикшерү вакытында гомуми баланс бәясе 6 200 мең сум булган 8 берәмлек казна милкенең финанс булмаган активларының (гомуми белем бирү мәктәпләре, балалар бакчалары, хастаханә биналары) файдаланылмаганлыгы ачыкланды.

Югары Балтай авылы, С.Сәйдәшев урамы, 79нчы йорт адресы буенча урнашкан гомуми белем бирү мәктәбе бинасы

Кормаш авылы, Яшьләр урамы, 41нче йорт адресы буенча урнашкан балалар бакчасы бинасы

Апас муниципаль районының Ишәй һәм Иске Йомралы авыл җирлеге башкарма комитетында тәмамланмаган төзелеш объектлары составында гомуми бәясе 4 700 мең сум булган 2013 елның гыйнварендә һәм 2014 елның ноябрендә файдалануга тапшырылган ике авыл клубы (Мәҗек һәм Карабай авылларында) санала.

Ишәй авыл җирлегенең Мәҗек авылында һәм Иске Йомралы авыл җирлегенең Карабай авылындагы авыл клублары

Тутай авыл җирлеге башкарма комитетының төп чаралар составында ялгыш 800 мең сумлык баланс бәясе белән Сара Садыйкова музее бинасы санала, чынбарлыкта ул «Апас туган якны өйрәнү музее» МБУ филиалы булып тора.

Балык Бистәсе муниципаль районы Шомбыт, Казаклар Чаллысы, Балтач авыл җирлекләрендә һәм Балык Бистәсе штб. дә гомуми баланс бәясе 9 068,8 мең сум булган милек (автотранспорт, административ һәм торак биналар, авыл хуҗалыгы техникасы) озак вакыт дәвамында (3 елга кадәр) файдаланылмаган.

2015 елда Нурлат муниципаль районының «ТКХ идарә компаниясе» ҖЧҖ Яңа Иглай авылы җирлегенең Якты күл торак пунктында төзегән 947 мең сумлык сууткәргеч скважинада су булмау сәбәпле файдаланылмаган.

Җирләрне һәм муниципаль милекне арендага алган өчен түләүнең тулылыгын һәм үз вакытында булуын тикшерү вакытында аерым кимчелекләр һәм җирле бюджетның керем өлешен тутыруның булган резервларын ачыклады.

Бөгелмә, Зәй һәм Чистай муниципаль районнарында тикшерүләр гомумән алганда җир кишәрлекләренең аренда һәм сату-алу килешүләре сатулашулар үткәрмичә генә башкарылуын билгеләде, бу җирле бюджетны тутыруга ярдәм итмәгән.

Мәсәлән, 2015 ел өчен Бөгелмә муниципаль районында сатулашуларда 1 кишәрлек сатылган, ә сатулашуларсыз – 318 кишәрлек. 2015 елда җир кишәрлекләре сатудан 10 685 мең сум, сатулашулар нәтиҗәләре буенча бары тик 32 мең сум акча керә.

Апас муниципаль районының җирле бюджетына каты көнкүреш калдыклары полигонында торак булмаган бинаны һәм физик һәм юридик затларга җир кишәрлекләрен (36 җир кишәрлеге) арендага бирүдән кереп җитмәгән чаралар 370 мең сум тәшкил итә.

Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләренең максатчан файдаланылмау очраклары да ачыклана.

Чистай муниципаль районында Түбән Кама шәһәренә бара торган трасса буена урнашкан җирләрдә шәхси сервис (кафе, автомобильләрнең туктап тору урыны, ягулык салу станциясе, шиномонтаж) юл хезмәтләре эшләп килгән.

Түбән Кама шәһәренә бара торган трасса буендагы җирләрдә урнашкан сервис юл хезмәтләре объектлары

Җир законнарын бозуның барлык фактлары буенча тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар

министрлыгына һәм җир күзәтчелеген тормышка ашыручы башка органнарга җибәрелде.

Кукмара штб.нең 3 йортында 2014 елда үткәрелгән капиталь ремонт кысаларында җылылык белән тәэмин итү системасын ремонтлау буенча эшләр башкарыла. 2015 елда стена казаннары белән шәхси җылытуга күчү сәбәпле, күрсәтелгән җылылык белән тәэмин итү системасы тулысынча сүтеп алынды. Гомуми күләме 3 737 мең сум булган әлеге эшләр бюджет чараларының нәтиҗәлелеге һәм файдалылыгы принцибын сакламыйча уздырылган.

Кукмара штб. дә элек капиталь ремонт үткәрелгән торак йортның сүтеп алынган җылыту системасы

Апас муниципаль районында районның 21 авыл җирлегенең «Татинвестгражданпроект» ДУП белән төзелгән муниципаль контрактлары шартларын бозып, генераль планнар һәм җир файдалануы кагыйдәләрен һәм җирлекләрдә йортлар салуны эшләү буенча элегрәк түләнгән (2015 елның декабрендә) гомуми күләме 3 700 мең сум булган проект эшләре куелган вакытка (2016 елның 29 февраленә кадәр) бирелмәгән.

Бөгелмә муниципаль районында алыш-биреш уздыру вакытында эшне башкаруның минималь сроклары билгеләнгән. Нәтиҗәдә, аукционда катнашучыларның саны баштан ук чикләнгән була, һәм, шул рәвешле, башлангыч бәя бик азга гына – 1% тан да артык булмаган күләмдә генә – төшкән. Тикшерү барышында шунысы да ачыкланды: хезмәтләр чынбарлыкта контрактлар төзегәнче яисә билгеләнгән срокларны, аерым очракларда 123 көнгә кадәр, бозып, башкарылган булган. Шул ук вакытта контрактлар үтәлешен вакытларын үтәмәгән өчен неустойка түләтү буенча чаралар күрелмәгән.

Чистай муниципаль районында кайбер очракларда хезмәтләр шулай ук чынбарлыкта контрактлар төзегәнче яисә билгеләнгән срокларны, аерым очракларда 153 көнгә кадәр, бозып, башкарылган булган. Шул ук вакытта контрактлар үтәлеше вакытларын үтәмәгән өчен неустойка түләтү буенча шулай ук чаралар күрелмәгән. Моңардан тыш, гомуми күләме 31 164 мең сум булган 25 муниципаль контрактта һәм килешүдә мәҗбүри шарт – эшләрнең (хезмәт күрсәтүләрнең) үтәлү вакытлары язылмаган.

Нурлат муниципаль районынның белем бирү мәктәпләренең автотранспорт предприятиесе белән төзелгән муниципаль контрактлары нигезендә 2016 елның гыйвар-май айларында укучыларны йөртү буенча хезмәтләр күрсәтелгән. Бәягә гомуми күләме 222,4 мең сум булган мәктәп автобусларын автотранспорт предприятиесенең гаражында тоту өчен чыгымнар да кергән. Транспорт чынбарлыкта туктап тору урыннарында һәм белем бирү оешмаларының гаражларында торган.

Тикшерү барышында автотранспорт предприятиесенә күрсәтелмәгән хезмәтләре өчен акчаларны кире кайтару таләбе куелды.

Районның белем бирү учреждениеләренә китерелә торган туклану продуктларының вакытында китерелүен һәм сыйфатын тикшерү төзелгән муниципаль контрактларның шартларын бозуларны ачыклады.

Мәсәлән, Әлки муниципаль районында гомуми күләме 1 600 мең сум булган туклану продуктлары аларны сыйфатын дәлилләүче тиешле документлардан башка китерелгән.

Бөгелмә районы белем бирү учреждениеләре хаҗәтләре өчен азык-төлек продуктларын үзәкләштерелгән сатып алулар уздырыла. Мәсәлән, 2015 елда иттән ясалган эшләнмәләр белән тәэмин итүгә мәгариф учреждениеләре «Мясоопт» ҖЧҖ һәм «Империя+» ҖЧҖ белән муниципаль контрактлар төзиләр. Беренче очракта бердәнбер тәэмин итүче, икенчесендә – көндәшлек нигезендә. Нәтиҗәдә бер үк җитештерүче продукциясе муниципаль районның бюджет учреждениеләренә күпкә, аерым очракларда 2 тапкыр, аерылып тора торган бәяләр белән китерелә.



Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләр башлыкларына ачыкланган бозуларны юкка чыгаруны тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасының күрсәтмәләре җибәрелде.

Административ хокук бозулар фактлары буенча Хисап палатасы инспекторлары тарафыннан Әлки, Апас, Бөгелмә, Нурлат һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары учреждениеләре һәм оешмаларының вазыйфаи затларына карата тиешле беркетмәләр төзелде.

Татарстан Республикасы Хисап палатасы уздырган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча бюджет чараларын куллану, республика (муниципаль) милкеннән файдалану вакытында ачыкланган һәм башка финанс бозулары буенча бозулар һәм кимчелекләрне юкка чыгару буенча гомуми күләме **1 363 516,6 мең сум** (ачыкланган бозулар күләменең 87%ы) булган чаралар күрелгән, шулардан 174 566,7 мең сумы – Татарстан Республикасының консолидацияләнгән бюджетына кире кайтарылган, 1 188 949,9 мең сумлык чаралар күрелгән.

Министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозулар буенча **16** күрсәтмә һәм **57** мәгълүмати хат җибәрелде.

Барлык тикшерү чаралары буенча материаллар һәм ачыкланган бозулар турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Прокуратурасына җибәрелде.

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында Кодексына 2013 һәм 2015 елларда кертелгән үзгәрешләрне истә тотып, тышкы дәүләт тикшерүе органнары вазыйфаи затларының вәкаләтләре өлкәсе

сизелерлек киңәйде һәм административ хокук бозуларның 27 составын үз эченә ала.

Хисап палатасының инспекторлар составы финанс-бюджет законнарын бозучыларны административ җаваплылыкка тарту буенча актив эш алып бара.

Ачыкланган финанс бозу фактлары буенча административ хокук бозулар турында 115 беркетмә төзелгән.

Уздырылган тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча **административ җаваплылыкка** гомуми күләме 394 мең сум булган штраф рәвешендә **5** юридик зат һәм **39** вазыйфаи зат тартылган.

Дисциплинар җаваплылыкка Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча **74** вазыйфаи зат тартылган, шуларның 6 сы – биләгән вазыйфаларыннан азат ителгән.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары, тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының

Хисап чорында Татарстан Республикасы Хисап палатасының Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, региональ тикшерү-хисап органнары, шулай ук тышкы финанс тикшерүе региональ органнарының Европа оешмасы (алга таба – ЕВРОРАИ) белән үзара хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эше дәвам иттерелде.

2016 елның февралендә Хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасы региональ тикшерү-хисап органнары вәкилләре белән берлектә оештырган гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннын күчерүгә бюджет чараларын файдалану белән бәйле тикшерү һәм экспертиза-аналитика чараларының көнүзәк мәсьәләләре, максатлары һәм бурычлары буенча видеоконференциядә катнашты.

Видеоконференция йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан муниципаль берәмлекләрдә Хисап палатасының комплекслы тикшерүләре барышында карау өчен зарур булган гражданнарны авария хәлендәге торактан күчерү программасын тормышка ашыруны тикшерү өлешендә мәсьәләләр исемлеге әзерләнде. Исемлек шулай ук тикшерү чаралары үткәргәндә куллану өчен республиканың муниципаль тикшерү-хисап органнарына да җибәрелде.

Апрельдә Санкт-Петербургта Россия Федерациясе Хисап палатасы аудиторы С.А. Агапцов рәислегендә «Дәүләт инвестицияләре катнашында алып барылган киң масштаблы проектларның нәтиҗәлелек аудиты» мәсьәләсенә багышланган Россия-Кытай икеяклы семинарының икенче секциясе булып узды. Аның эшендә Санкт-Петербург хөкүмәте, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумы әгъзалары, Төньяк-Көнбатыш федераль округка керә торган регионнарның тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре катнашты.

Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов Татарстанда нәтиҗәлелек аудитын үткәрү тәҗрибәсе турындагы доклад белән чыгыш ясады. А.И.Демидов үз чыгышында семинарда катнашучыларга Татарстан Республикасы тарафыннан Кытайның 3 провинциясе (Шаньдун, Сычуань и Хунань) белән күпъяклы хезмәттәшлек итү турында төзелгән килешүләр һәм аммиак, метанол һәм гранулалаштырылган карбамид җитештерү буенча «Аммоний» АҖ комплексын төзү, шулай ук Европа – Көнбатыш Кытай автоюлының бер өлешен салу кебек эре инвестиция проектларын тормышка ашыру, Мәскәү – Казан югары тизлекле тимер юл магистрален төзү буенча планнар турында сөйләде.

Чыгыш барышында шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы белән берлектә 2013 елда Казанда үткәрелгән Бөтендөнья җәйге Универсиаданы оештыру, әзерләү һәм үткәрүгә юнәлдерелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү турында искә төшерделәр.

Апрельдә Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы А.Р.Вәлиев Мәскәүдә Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре өчен уздырылган «Нәтиҗәлелек аудиты – тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенең өстенлеге» дип аталган фәнни-гамәли семинарда катнашты һәм, төп докладчыларның берсе булып, Татарстан Республикасы Хисап палатасы мисалында дәүләт чараларын кулланган чакта нәтиҗәлелек аудитын үткәрү тәҗрибәсе белән уртаклашты.

Апрельдә составына Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Казан шәһәренең Тикшерү-хисап палатасы вәкилләре кергән Татарстан Республикасы делегациясе Санкт-Пельтен (Австрия) шәһәрендә узган ЕВРОРАИның халыкара семинарында катнашты.

Семинар кысаларында махсус рәвештә эшче төркеме тарафыннан эшләп чыгарылган һәм ЕВРОРАИның Идарә Комитеты тарафыннан расланган методик документ – «Тышкы дәүләт финанс тикшерүенең (аудит) бәйсез региональ органнары эшчәнлеге өчен кулланма» (алга таба – Кулланма) тәкъдим ителде.

Әлеге документта тикшерү-хисап органнары эшчәнлеге өчен нигез булып санала торган һәм, Кулланманы уйлап табучылар фикеренчә, тышкы финанс тикшерүенең региональ органнарының әһәмиятен көчәйтү коралы булып торган 15 принцип тәкъдим ителгән.

Июньдә Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Россия Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов аудиторларның Санкт-Петербургта узган халыкара икътисадый форумы кысаларында үткән «Икътисадый сәясәт коралы буларак бюджет үзенчәлекләре» дип аталган ачык дискуссиясендә катнашты.

Арасында Россия Федерациясе Хисап палатасы Рәисе Т.А.Голикова, Россия Федерациясе финанс министры А.Г.Силуанов, Россиянең әйдәп баручы икътисадчылары һәм финансчылары халыкара финанс тармагы вәкилләре булган аудиторларның ачык дискуссиясендә катнашучылар икътисадый сәясәт коралы буларак бюджет мөмкинлекләре, шулай ук дәүләт ярдәмен ала торган үсеш институтларының нәтиҗәлелек мәсьәләләре, финанс тикшерүенең югары органнарының бюджет процессындагы роле һәм урыны турында фикер алыштылар.

2016 елның июлендә Хисап палатасы аудиторы А.Р.Вәлиев һәм Хисап палатасының оештыру эшләре мөдире М.А.Вьюгина тәҗрибә уртаклашу максаты белән Вьетнам Социалистик Республикасына барып кайтты. Әлеге визит Вьетнамның Аудит буенча дәүләт идарәсе (алга таба – Дәүләт идарәсе) чакыруы буенча һәм аның чаралары хисабына узды.

Татарстан Хисап палатасы вәкилләре Ханой (тыңлаучылар саны – 50дән артык) һәм Хо Ши Мин (30дан артык тыңлаучы) шәһәрләрендә Дәүләт идарәсе белгечләре өчен дәүләт чараларын нәтиҗәле кулларга аудит үткәрү методологиясе һәм гамәлияте мәсьәләләре буенча лекцияләр укыды, Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлегенең төп юнәлешләре тәкъдим итте. Уку барышында чит илдәге хезмәттәшләр республика Хисап палатасы тарафыннан Россия-Канада һәм Россия-Британия проектлары кысаларында Россия Федерациясе Хисап палатасы белән бергә тормышка ашырылган, шулай ук Татарстан Хисап палатасы вәкилләренең Сингапур Республикасында узган стажировкасы вакытында тупланган нәтиҗәлелек аудитын үткәрү тәҗрибәсе турында мәгълүмат алды.

Июльдә Татарстан Республикасы Хисап палатасына Рәисе А.А.Заиченко җитәкчелегендә Кырым Республикасы Хисап палатасы делегациясе килде. Эшлекле очрашу барышында Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Кырым Республикасы Хисап палатасы арасында үзара хезмәттәшлек турында Килешүгә кул куелды.

Июль һәм август айларында Хисап палатасында Ставрополь крае Тикшерү-хисап палатасы Рәисе А.А.Колесников; составына Ингушетия

Республикасы Тикшерү-хисап палатасы Рәисе М.К.Белхароев, Ингушетия Республикасы Халык Җыены Аппараты Җитәкчесе М.Ж.Яндиев кергән Ингушетия Республикасы делегациясе белән эшлекле очрашулар булып узды.

Сентябрьдә Уфа шәһәрендә Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советының Идел буе федераль округындагы бүлекчәсе Рәисе, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе

А.И.Демидов Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары җитәкчеләренең «Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан үткәрелә торган бурыч сәясәте өлкәсендә дәүләт финанс тикшерүенең мөһим мәсьәләләре һәм бюджет үтәлешенә һәм регионнарның социаль-икътисадый үсешенә аның тәэсире» дип аталган фәнни-гамәли конференциясендә катнашты, һәм Татарстан Республикасында дәүләт бурычы белән идарә итү, әлеге өлкәдә тышкы дәүләт финанс тикшерүе буенча вәкаләтләрне башкару буенча алып барылган эш турында чыгыш ясады.

Октябрьдә Нант шәһәрендә (Франция) Европа Региональ тикшерү-хисап органнары ассоциациясенең (ЕВРОРАИ) «Социаль тәэминат өлкәсендә тышкы дәүләт финанс тикшерүенең регионнардагы органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган аудит» темасына багышланган IX Конгрессы һәм Генераль Ассамблеясе утырышы булып узды. Конгресс барышында турыдан-туры социаль ярдәм алучыларга күрсәтелә торган социаль ярдәм аудиты, шулай ук социаль тәэминат буенча функцияләрне башкара торган социаль тәэминатның халык алдындагы органнары һәм социаль тәэминат функцияләрен башкаручы шәхси оешмаларны тикшерү аудиты белән бәйле мәсьәләләр каралды. Әлеге мәсьәлә буенча Шотландия, Уэльс, Испания, Швейцария, Австрия, Германия һәм Польшаның төрле регоннарыннан килгән хисап палаталары вәкилләре чыгыш ясады.

Генераль Ассамблея утырышында ЕВРОРАИның яңа Президенты – Луара Жиренең (Франция) Региональ Хисап палатасы җитәкчесе Франсуа Монти сайланды. Шулай ук берничә оештыру мәсьәләсе, шул исәптән киләсе өч еллык чор өчен эш планын төзү мәсьәләләре буенча фикер алышу узды. ЕВРОРАИның җитәкче комитеты тарафыннан карауга оешма әгъзалары булган 6 орган тарафыннан 2017 елда тематик семинар-киңәшмәләр уздыру буенча тәкъдимнәр кертелде. Бертавыштан 2017 елның маенда Казан шәһәрендә «Спорт өлкәсендә дәүләт инвестицияләренең нәтиҗәлелегенә аудит үткәрү (зур халыкара ярышлар мисалында)» мәсьәләләренә багышланган ЕВРОРАИ халыкара семинарын уздыру турында карар кабул итте. Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов үз чыгышында эре спорт ярышларын оештыру һәм үткәрүгә бүлеп бирелгән чараларны тотуны тикшерү буенча билгеле бер тәҗрибә Татарстан Хисап палатасы тәкъдим иткән ЕВРОРАИның 2017 елда узачак семинарында тикшерелә торган теманы сайлауга этәргеч булып торганлыгын билгеләп үтте. Соңгы елларда республика башкаласында Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарының, Европа һәм дөнья дәрәҗәсендәге спортның кышкы һәм җәйге төрләре буенча күпсанлы эре халыкара ярышлар уңышлы узды. 2013 елдагы Бөтендөнья студентлар уеннарын әзерләү, оештыру һәм уздыруга бүлеп бирелгән бюджет чараларын файдалануның нәтиҗәлелеге мәсьәләләре 4 ел дәвамында Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Татарстан Республикасы Хисап палатасының даими тикшерүе астында булды.

Декабрьдә видеоконференция форматында Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясе утырышы узды. Анда 2 экспертиза-аналитика чарасының («Россия Федерациясе субъектлары юл хуҗалыкларының бюджет ассигнованиеләрен формалаштыру һәм куллануга анализ»

һәм «2014-2015 елларда һәм 2016 елның узган вакыт аралыгында мәҗбүри медицина иминияләштерүендә катнашучылар буларак иминият медицина оешмалары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү») нәтиҗәләре каралды. Утырыш нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясе тарафыннан кабул ителгән карарларны тормышка ашыру буенча Чаралар планы эшләнде.

Декабрьдә Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумы әгъзасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов «Өстенлекле проектларны тормышка ашырган чакта аудитның роле һәм урыны турында» темасына багышланган Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы һәм Президиумының берләштерелгән утырышында катнашты. Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы Рәисе, Россия Федерациясе Хисап палатасы Рәисе Т.А.Голикова Россия регионнарындагы тикшерү-хисап органнарының 2017 елдагы эш планнарын төзүгә аерым игътибар юнәлтте – Россия Федерациясе Президенты В.В.Путинның Федераль Җыелышка булган еллык Юлламасында куелган өстенлекле бурычларны финанслау һәм үтәү мәсьәләләре буенча тикшерү чараларын кертү кирәклеген, шулай ук өстенлекле проектларны төзегәндә һәм тормышка ашырган чакта мониторинг һәм тикшерү үткәрү кирәклеген ассызыклады.

Утырыш барышында шулай ук Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары Советы Президиумының персональ составы расланды. Аңа 2016 елның ноябрендә яңа өч еллык вакытка Советның Идел буе федераль округындагы бүлекчәсе Рәисе итеп сайланган Татарстан Республикасы Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидов та керде.

Республика Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе Хисап палатасының системалы анализ буенча дәүләт фәнни-тикшеренү институты (алга таба – ФТИ) хезмәттәшлеге кысаларында Хисап палатасы аудиторы

А.Р.Вәлиев хисап чорында Петропавловск-Камчатский шәһәрендә узган «Муниципаль тикшерү-хисап органнарында административ җитештерүне кертү мәсьәләләре һәм тәҗрибәсе» дип аталган семинарда катнашты; ФТИның Себер федераль округындагы филиалы тарафыннан оештырылган видеоконференциядә «Татарстан Республикасында сатып алулар аудитын тормышка ашыру тәҗрибәсе» мәсьәләсенә багышланган доклад белән чыгыш ясады. Аудитор шулай ук Ерак Көнчыгыш федераль округы, Кырым Республикасы тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре, Мәскәүдә региональ һәм муниципаль тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре өчен квалификация күтәрү курсларын үткәрүдә катнашты.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары, Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары союзы белән үзара хезмәттәшлек

2016 елда Татарстан Хисап палатасы муниципаль финанс тикшерүе нәтиҗәлелеген арттыруга, республика тикшерү-хисап органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшен дәвам иттерде.

Муниципаль тикшерү-хисап палаталарына оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати, шул исәптән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелегенә аудит оештыру һәм үткәрү буенча ярдәм күрсәтелә. Барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округларының тикшерү-хисап органнарына кураторлар – Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторлары һәм структура бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелә. Даими рәвештә тикшерү һәм экспертиза-аналитика чараларын, муниципаль берәмлекләрнең бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелек аудитын, муниципаль хаҗәтләр өчен сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү мәсьәләләре буенча консультация бирү тормышка ашырыла.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг үткәрелә.

2016 елда Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары тарафыннан 727 тикшерү чарасы уздырылган. Тикшерү 1 787 объектны колачлаган. Тикшерү нәтиҗәләре буенча чаралар күрелгән һәм республиканың муниципаль берәмлекләре бюджетларына 2 780,2 млн. сум күләмендә чара кире кайтарылган.

Муниципаль тикшерү-хисап органнары җирле үзидарә органнарының муниципаль берәмлек бюджет чаралары исәбенә чыгымнарны күз алдында тоткан һәм аны формалаштыру һәм үтәлешенә йогынты ясый торган норматив хокук актлары проектларына экспертиза үткәрә. 2016 елда 2 164 экспертиза-аналитика чарасы үткәрелгән, 2 011 эксперт бәяләмәсе әзерләнгән.

Июньдә Вологда шәһәрендә Россия Федерациясе Муниципаль тикшерү-хисап органнары Союзының Гомуми җыелышы узды, аның эшендә 11 муниципаль тикшерү-органнары һәм республика Хисап палатасы вәкилләреннән торган Татарстан Республикасы делегациясе дә катнашты.

Форум барышында түгәрәк өстәлләр һәм дискуссия мәйданчыклары эше оештырылды. Анда Яр Чаллы шәһәре, Түбән Кама муниципаль районы тикшерү-хисап палаталары рәисләре һәм Казан шәһәре Тикшерү-хисап палатасы Рәисе урынбасары актив катнашты һәм докладлар белән чыгыш ясады. Модераторлар тарафыннан Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм муниципаль тикшерү-хисап органнарыың уңышлы хезмәттәшлеген, шулай ук Татарстан Хисап палатасының нәтиҗәлелек аудитын үткәрүдәге уңай тәҗрибәсе билгеләп үтелде.

Сентябрьдә Казан шәһәрендә «Бюджет» Нәшрият йорты һәм «Бюджет» уку үзәге (Мәскәү) Идел буе федераль округы белгечләре өчен «Эчке дәүләт финанс тикшерүе, эчке финанс тикшерүе һәм аудитын тормышка ашыруның актуаль мәсьәләләре» дип аталган семинар-конференция узды.

Семинар эшендә Татарстан Хисап палатасы һәм республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары хезмәткәрләре катнашты. Чара кысаларында дәүләт ихтыяҗы өчен

башкарылган сатып алулар методологиясе һәм тикшерүне оештыру мәсьәләләре, эчке тикшерү һәм аудитны оештыру һәм үткәрү буенча гамәли киңәшләр, эчке контроль системасын төзү буенча Татарстан тәҗрибәсе каралды. Татарстан Хисап палатасы аудиторы Азат Вәлиев «Дәүләт финанс тикшерүе органнарының үзара хезмәттәшлек итүе, кисәтү буенча эшчәнлеге: Татарстан Республикасы тәҗрибәсе» дигән темага чыгыш ясады, Татарстан Респбликасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советының эш тәҗрибәсе турында сөйләде.

2016 елның декабрендә булып узган Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары Советы утырышында «программалы» бюджетка күчү кысаларында тышкы финанс тикшерүе органнары эшчәнлеге; дәүләт (муниципаль) милке белән идарә итү һәм файдалану өлкәсендә бозулар һәм кимчелекләрне ачыклау буенча тикшерү эшчәнлеге практикасы; тышкы финанс тикшерүе органнары вәкаләтләрен тормышка ашыру өлкәсен көйләү; Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы хуплаган Тышкы дәүләт аудиты (тикшерүе) барышында ачыкланган бозулар Классификаторын куллану мәсьәләләре каралды. Казан шәһәре һәм Түбән Кама муниципаль районы Тикшерү-хисап палаталары рәисләре административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзү буенча вәкаләтләрен тормышка ашыру һәм сатып алуларга аудит үткәрү практикасы турында чыгышлар ясады.

2017 елга республиканың муниципаль тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре сыйфатында:

- финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм булдырмау профилактикасы;
- тикшерү чаралары йомгаклары буенча ачыкланган бозуларны юкка чыгару буенча тикшерелгән оешмалар тарафыннан чараларны тормышка ашыру буенча эшне активлаштыру;
- муниципаль сатып алулар өлкәсендә аудит үткәрү;
- муниципаль берәмлекләрдә социаль-мәдәни объектлар төзелешенә, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтка бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллану мәсьәләләре буенча тематик тикшерү, шулай ук төзелеш барышында бәянең типовой нормативларын саклау һәм мәйданнарын ачыклау чаралары уздыру билгеләнде.

Утырышта шулай ук «Татарстан Республикасының иң яхшы финанс контролеры» бәйгесенә йомгак ясалды. 2016 ел җиңүчеләре дипломнарын Татарстанның Алабуга һәм Яңа Чишмә муниципаль районнарының тикшерү-хисап органнары рәисләре алды.

Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге һәм үткәрелә торган чаралар турында мәгълүмат, норматив һәм методик документлар Татарстан Хисап палатасының (http://www.sprt.tatar/) һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советының (http://www.ksort.ru) рәсми сайтларында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән үзара хезмәттәшлек

2016 елда Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы (алга таба – Совет) кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы тарафыннан алып барылган эш дәвам иттерелде. Финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеге Тикшерү чараларының җыелма планына туры китереп тормышка ашырылды.

Финанс-бюджет өлкәсендә бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатында министрлыкларга, ведомство һәм республиканың муниципаль берәмлекләренә ел саен дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары тарафыннан ачыклана торган бозулар һәм кимчелекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча Бәяләмә җибәрелә.

Советның апрельдә булып узган утырышында берничә актуаль мәсьәлә каралды. Аерым алганда, тикшерелгән оешмалар җитәкчеләре һәм югарырак тора торган органнар тарафыннан финанс тикшерүе органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәсендә кабул ителә торган карарлар һәм чараларның нәтиҗәле булу-булмау мәсьәләсе каралды. Утырыш нәтиҗәләре буенча Совет Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына финанс тикшерүе органнары тарафыннан ачыкланган бозуларга китергән хәлләрне (сәбәпләрен һәм шартларын) бәяләү буенча чаралар үткәрүгә карата системалы һәм

бертөрле карашны тәэмин итә торган һәм җаваплы вазыйфаи затларның гаебе барлыгын таный торган акт кабул итү турында инициатива белән чыкты.

Бюджет чараларын кулланган чакта финанс дисциплинасын ныгыту максатында Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә бюджет чараларын төп кулланучылар тарафыннан административ җаваплылыкка тартылырга мөмкин булган гамәлләр билгеләренә ия булган бозуларны ачыклаган чакта гамәлләрнең бердәм тәртибен (регламентын) эшләп чыгару турында тәкъдим кертелде.

Утырыш кысаларында шулай ук муниципаль берәмлекләрдә җир ресурслары белән идарә итү һәм алардан файдалану өлкәсендәге бозулар турында мәсьәлә каралды. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча муниципаль берәмлекләрдә җир ресурслары белән идарә итү һәм алардан файдалануны ведомствоара системалы тикшерүне, җир мөнәсәбәтләре өлкәсендә законлылыкны тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү буенча эшче төркем төзү турында карар кабул ителде.

Хисап чорында эшче төркемнең 2 утырышы, шул исәптән Болгар шәһәрендә күчмә утырыш булып узды. Җир ресурслары белән идарә итү һәм алардан файдалану буенча ведомствоара системалы тикшерүне оештыру буенча Методик тәкъдимнәр (алга таба – Методик тәкъдимнәр) әзерләнде, аларда җир мөнәсәбәтләре тармагындагы төп бозулар һәм җитешсезлекләр системалаштырылды, куркынычлар белән идарә итү буенча чаралар тәкъдим ителде.

Декабрьдә Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы утырышында вәкаләтле дәүләт һәм муниципаль органнар тарафыннан җир ресурслары белән идарә итү һәм алардан файдалану өлкәсендәге тикшерүне көчәйтү буенча чаралар күрү турындагы мәсьәләне карау барышында әлеге Методик тәкъдимнәр хупланды.

Документны гамәли яктан эштә куллану һәм идарә карарлары кабул итү өчен Татарстан Республикасы Президентына, муниципаль берәмлекләргә, шулай ук республиканың җир тармагындагы тикшерүне һәм күзәтчелекне тормышка

ашыра торган министрлык һәм ведомстволарга юллау турында карар кабул ителде.

Февральдә Хисап палатасы Рәисе А.И.Демидовның Гомумроссия халык фронтының Татарстан Республикасындагы региональ бүлекчәсе җитәкчеләре белән булган эшлекле очрашуы кысаларында Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» Гомумроссия

иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы Региональ бүлеге арасында бюджет чараларын куллануны һәм дәүләт милке белән идарә итүне тикшерү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өлкәсендә үзара хезмәттәшлек, шул исәптән дәүләт хаҗәтләре өчен сатып алуларны тормышка ашыру кысаларында, конкрет чаралар барышында эш тәҗрибәсе һәм эшчәнлек нәтиҗәләре белән алмашу турында Килешүгә кул куйдылар.

Сентябрьдә Хисап палатасы аудиторы С.Е.Колодников Татарстан Республикасы Дәүләт Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча комитеты утырышында катнашты һәм республиканың Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм аңа караган учреждениеләр тарафыннан энергетика ресурсларыннан файдаланган чакта Татарстан Республикасы һәм Мәҗбүри медицина иминиятләштерүенең территориаль фонды бюджетлары чараларын куллануга карата үткәрелгән нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары турында доклад белән чыгыш ясады. Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән нәтиҗәлелек аудиты йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең медицина учреждениеләре җитәкчеләре белән киңәшмә булып узды.

Декабрьдә Коррупциягә каршы халыкара көн кысаларында Татарстан Хисап палатасында Татарстан Республикасы Президенты Аппараты вәкилләренең Хисап палатасы коллективы белән эшлекле очрашуы узды. Очрашу барышында Татарстан Республикасында коррупциягә каршы тору буенча эшне координацияләү буенча Комиссиянең эксперт төркеме эше

турында, кызыксынулар һәм шәхси кызыксынучанлык конфликты килеп чыгу, дәүләт гражданлык хезмәткәрләре һәм аларның гаилә әгъзалары тарафыннан керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы бурычлар турында мәгълүмат бирү мәсьәләләре турында фикер алышу узды.

Хисап чорында Хисап палатасы хезмәткәрләре Татрстан Республикасы Президенты Аппараты, Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарәнең югары мәктәбе тарафыннан оештырылган Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларын үткәрүдә катнашты.

Эшчәнлектә хәбәрдарлык

2016 елда Татарстан Республикасы Хисап палатасы эшчәнлеге, Хисап палатасы Коллегиясе, Татарстан Республикасында дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү Советы һәм Татарстан Республикасы тикшерү-хисап органнары Советы утырышлары даими рәвештә массакүләм матбугат чараларында яктыртылып торды.

Хисап чорында массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет басмалар, журналлар, газета һәм телевидение) Хисап палатасы эшчәнлеге 291 материалда, шул исәптән федераль һәм региональ басмаларда: «Интерфакс-Поволжье», «РБК», «РЕГНУМ» мәгълүмат агентлыкларының веб-сайтларында, «E-gorlovka.com.ua», «Нева-инфо», «Урал.ru», «EraNews.ru», «163Город.ru» (Самара өлкәсе), «Мангазея» (Петропавловск-Камчатский), «Оренбургские новости» веб-сайтларында, «Аргументы и Факты», «Коммерсантъ», «Комсомольская правда», «Российская газета», «МК»

газеталарының региональ чыгарылышларында, «Вестник АКСОР», «Татарстан», «Эксперт в Татарстане», «Чаян» журналларында тәкъдим ителде.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат рәсми сайтта (http://www.sprt.ru), Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары порталында (http://www.portalkso.ru) урнаштырылды.

2016 елда Хисап палатасы сайтына 29 463 тапкыр керү теркәлгән (2015 елда – 29 195, 2014 елда – 28 548, 2013 елда – 26 928).

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары квартал саен Татарстан Республикасы Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә басылып чыкты. Бюллетеньнар Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына юлланды.